# Хәл

*Җөмләдә эш яки хәрәкәтнең кайда, ничек, кайчан, ни сәбәпле, нинди шартларда үтәлү-үтәлмәвен белдереп, **фигыльгә** ияргән яки, билгенең дәрәҗәсен белдереп, **сыйфатка, рәвешкә** ияргән иярчен кисәк.*

**Сораулары:** ***кайда? кайчан? ничек? никадәр? ник? ни өчен? нилектән? нинди максат белән? нишләсә? нәрсәгә карамастан? һ.б.***


Хәл төркемчәләре
Вакыт хәле
Урын хәле
Сәбәп хәле
Максат хәле
Рәвеш хәле
Күләм хәле
Шарт хәле
Кире хәл

# Вакыт хәле

Эш-хәлнең **үтәлү вакытын** белдереп, **фигыльне** ачыклап килгән иярчен кисәк **вакыт хәле** дип атала.

***Борын заманда*** *бер ярлы гына карчык булган.* ***Шул вакытларда*** *патша үз янына вәзирен чакыра. Йөри-йөри, болар* ***кичкә*** *калалар.* ***Кичә*** *күргән төшеңне сөйлә. Бирегез үзенә биш камчы,* ***аннан соң*** *чыгарып ябыгыз.*



# Урын хәле

Эш-хәлнең **үтәлү урынын** белдереп, **фигыльне** ачыклап килгән иярчен кисәк **урын хәле** дип атала.

*Борын заманда **бер авылда** ярлы гына карчык булган. Шул вакытларда патша **үз янына** вәзирен чакыра. Йөри-йөри, болар **урманда адашып** калалар. **Урман читендә** бер алачык бар икән. Бирегез үзенә биш камчы, аннан соң **базга** чыгарып ябыгыз.*



# Сәбәп хәле

Эш-хәрәкәтнең **сәбәбен** белдереп, **фигыльгә** буйсынып килгән иярчен кисәк **сәбәп хәле** дип атала.

***Гел ялгыз булганга***, *тәмам кешеләрдән бизеп беткән икән.* ***Эшсезлектән*** *бөтенләй дә ялкауга әйләнгән. Болар* ***бер дә йөреп өйрәнмәү аркасында*** *адашып калалар. Урман читендә бер утны* ***күреп***, *алар бик шатлананалар. Бернәрсә дә* ***сөйләмәгән өчен*** *җәзасын ала.*

# Максат хәле

Эш-хәрәкәтнең нинди **ният (максат) белән үтәләчәген** белдереп килгән иярчен кисәк **максат хәле** дип атала.


***Белешеп кайту өчен***, *урманга чыгып китәләр.* ***Юл эзләргә,*** *иң кыю аучыны җибәрәләр. Ут күренгән берләнбер өйгә* ***төн кунарга*** *керәләр.* ***Төшен сөйләтү ниятеннән***, *егетне җәзалап та карыйлар.*



# Рәвеш хәле

Эш-хәрәкәтнең **ничек** үтәлүен белдереп килгән иярчен кисәк **рәвеш хәле** дип атала.

***Йөри-йөри,*** *болар урманда адашып калалар.* ***Киңәшләшеп,*** *алан уртасында бераз ял итеп алырга булалар. Алан читендә юл күргәч,* ***балалардай*** *шатланалар. Үзләре* ***тавыш-тынсыз*** *гына җыеналар да юл буйлап китеп баралар. Капчыкларын* ***аскан хәлдә*** *урман эченнән атлыйлар.*



# Күләм хәле

**Билгенең дәрәҗәсен** белдергән һәм **сыйфат** белән **рәвешкә ияреп (кайвакыт фигыльгә дә)** килгән иярчен кисәк.

*Борын заманда* ***бик*** *ярлы гына карчык булган.* ***Көне буе*** *урманда адашып йөриләр. Киңәшләшеп, алан уртасында* ***беразга*** *гына тукталырга булалар.* ***Аз*** *гына ял итеп алалар да юлларын дәвам итәләр.* ***Ярты төнгә чаклы*** *баруларын дәвам итәләр.*



# Шарт хәле

Эш-хәрәкәтнең **шартын** белдереп, **фигыльгә** буйсынып килгән иярчен кисәк **шарт хәле** дип атала.

***Әзләсәләр***, *әлбәттә, үзләре үк табарлар иде.* ***Әйткән икән*** *эшли дә эшли инде ул аны.* ***Ишеттеме***, *шунда ук таптыра башлый, ди.* ***Тырышса,*** *һәркем булдыра ала.*



# Кире хәл

Көтелгән эш-хәрәкәтнең **киресен** белдереп, **фигыльгә** буйсынып килгән иярчен кисәк **кире хәл** дип атала.

***Эзләсәләр дә**, бернәрсә таба алмадылар. **Алдан әйткән булуына карамастан,** берни дә эшләнмәгән иде әле. **Кая гына барма**, барыбер тынычлык таба алмассың. **Тырышса да** йоклап китә алмады бүген әби.*

